**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 2 октябрендәге 3323 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 3 апрелендәге 961 номерлы «Административ хокук бозу кораллары яки предметлары булган әйберләрне һәм административ хокук бозу турындагы эш буенча дәлил буларак әһәмияткә ия документларны мәҗбүри алу, саклау һәм мәҗбүри алынган әйберләрне һәм документларны бирү тәртибе турындагы инструкцияне һәм административ хокук бозу коралларын яки предметларын һәм административ хокук бозу турындагы эш буенча дәлил буларак әһәмияткә ия документларны мәҗбүри алу беркетмәсе формасын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль законнар нигезендә, Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы кодексының 27.10, 28.3 статьяларын, 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Татарстан Республикасы законын үтәү йөзеннән, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Казан шәһәренең җирле үзидарә органнарында административ хокук бозу коралларын (предметларын) һәм административ хокук бозу турындагы эш буенча дәлил буларак әһәмияткә ия документларны саклауның һәм юк итүнең бердәм тәртибен билгеләү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 3 апрелендәге 961 номерлы «Административ хокук бозу кораллары яки предметлары булган әйберләрне һәм административ хокук бозу турындагы эш буенча дәлил буларак әһәмияткә ия документларны мәҗбүри алу, саклау һәм мәҗбүри алынган

әйберләрне һәм документларны бирү тәртибе турындагы инструкцияне һәм административ хокук бозу коралларын яки предметларын һәм административ хокук бозу турындагы эш буенча дәлил буларак әһәмияткә ия документларны мәҗбүри алу беркетмәсе формасын раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 9 сентябрендәге 3166 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның исемен түбәндәге редакциядә бирергә:

**«Административ хокук бозу коралларын (предметларын) һәм административ эш буенча дәлил буларак әһәмияткә ия документларны мәҗбүри алу, саклау, мәҗбүри алынган коралларны (предметларны) һәм документларны бирү һәм юк итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»**;

1.2. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Административ хокук бозу коралларын (предметларын) һәм административ эш буенча дәлил буларак әһәмияткә ия документларны мәҗбүри алу, саклау, мәҗбүри алынган коралларны (предметларны) һәм документларны бирү һәм юк итү тәртибе турындагы нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә расларга»;

1.3. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Казан шәһәре Башкарма комитеты районнары администрацияләре башлыкларына тәэмин итәргә:

3.1. Нигезләмәне үз карамагындагы вазифаи затларга җиткерүне, аны өйрәнүне һәм куллануны оештыруны;

3.2. Нигезләмә буенча административ хокук бозу коралларының яисә предметларының сакланышын»;

1.4. түбәндәге эчтәлекле 3(1) пунктны өстәргә:

«3(1). Мәҗбүри алынган административ хокук бозулар коралларын (предметларын) юк итү комиссиясе составын әлеге карарга 3 номерлы кушымта нигезендә расларга»;

1.5. 1 номерлы кушымта исемен түбәндәге редакциядә бирергә:

**«Административ хокук бозу коралларын (предметларын) һәм административ эш буенча дәлил буларак әһәмияткә ия документларны мәҗбүри алу, саклау, мәҗбүри алынган коралларны (предметларны) һәм документларны бирү һәм юк итү тәртибе турында нигезләмә»**;

1.6. 1 номерлы кушымтаның I бүлегендәге 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә административ хокук бозу коралларын (предметларын) мәҗбүри алу, саклау, аларны бирү һәм юк итү тәртибен билгели»;

1.7. 1 номерлы кушымтаның I бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 1.3 пунктны өстәргә:

«1.3. Административ эш башкару турында эш карап тикшерелә һәм алып барыла торган административ хокук бозганда зат тарафыннан файдаланылган әйберләр, азык-төлек продукциясе, инвентарь, предметлар административ хокук бозу коралы яисә предметы булып санала»;

1.8. 1 номерлы кушымтаның II бүлегендәге 2.3 пунктында «Башкарма комитеты» сүзләрен «Башкарма комитеты районы (районнары) администрациясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.9. 1 номерлы кушымтаның III бүлегендәге 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.5. Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралы яисә предметы хуҗасы, мәҗбүри алынган милекне кире кайтаруны сорап, аны мәҗбүри алган вакыттан бер ай дәвамында мөрәҗәгать итмәгән очракта, ул гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә муниципаль милек дип таныла һәм юк ителергә тиеш»;

1.10. 1 номерлы кушымтага түбәндәге эчтәлекле IV бүлеген өстәргә:

**«IV. Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) юк итү**

4.1. Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) юк итү эшләрен оештыру, сыйфатсыз һәм (яисә) куркыныч азык-төлек продукциясеннән тыш, административ хокук бозулар коралларын (предметларын) хуҗасыз дип тану турында суд карары законлы көченә кергәннән һәм аларны муниципаль милеккә кабул иткәннән соң, Казан шәһәре Башкарма комитетының район (районнар) администрациясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Түбәндәге очракларда азык-төлек продукциясе сыйфатсыз һәм (яисә) куркыныч дип таныла:

- санитария һәм ветеринария-санитария кагыйдәләрендә һәм нормаларында, дәүләт стандартларында һәм техник документларында (алга таба – норматив һәм техник документлар) билгеләнгән мәҗбүри сыйфат һәм куркынычсызлык таләпләренә туры килми;

- продукциянең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тикшерүне гамәлгә ашыручы затта шик тудырмый торган сыйфатсызлык билгеләре булу;

- продукция җитештерүченең (продукция белән тәэмин итүченең) продукциянең килеп чыгышын, сыйфатын һәм куркынычсызлыгын раслый торган документлары, шулай ук билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән продукцияне сертификацияләү турындагы документлары булмау;

- үзлекләре әлеге төргә һәм продукция исеменә туры килми;

- маркировкасы норматив һәм техник документлар таләпләренә туры килми;

- яраклылык срогы билгеләнергә тиешле продукция өчен мондый срок билгеләнмәгән белән яки яраклылык срогы узган.

4.3. Сыйфатсыз һәм (яисә) куркыныч азык-төлек продукциясе аны муниципаль милек дип тану турында судка мөрәҗәгать итмичә юк ителергә тиеш.

4.4. Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) юк итү турындагы карар Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) юк итү комиссиясе тарафыннан кабул ителә.

4.5. Административ хокук бозу коралларын (предметларын) юк итү чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла»;

1.11. әлеге карарга кушымта нигезендә редакцияләнгән 3 номерлы кушымта өстәргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 2 октябрендәге
3323 номерлы карарына
кушымта

**Мәҗбүри алынган административ хокук бозу**
**коралларын (предметларын) юк итү комиссиясе составы**

Комиссия рәисе – Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең транспорт, икътисади үсеш һәм сәүдә мәсьәләләре буенча урынбасары;

Комиссия рәисе урынбасары – Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитеты рәисе

Комиссия әгъзалары:

Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе башлыгы;

Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы;

Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгы;

Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе башлыгы;

Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының җәмәгать куркынычсызлыгы мәсьәләләре һәм хокук саклау органнары белән үзара бәйләнешләр идарәсе башлыгы;

Казан шәһәре Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе башлыгы;

«Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры;

Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча);

Казан шәһәренең участок буенча вәкаләтле полиция хезмәткәрләре һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча).

________________